**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава Бетьковского сельского поселения Рыбно-Слободского муниципального района**
индекс 422649 , с.Бетьки ,ул.Мира, дом 2 телефон

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге башлыгы**
индекс 422649, Бәтке авылы, Тынычлык ур., 2 йорт
телефон

Тел.: (84361) 26235, факс: (84361) 26235, эл.адрес: Bet.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 8 ноябре Бәтке авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Бәтке, Кече Укмас һәм Яншык авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Бәтке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Яншык авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 18 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Бәтке авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 18 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Кече Укмас авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 19 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.

4.Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә кирәк.

5.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Бәтке,Яншык, Кече Укмас, Көек авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм

тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Бәтке авылы Ленин урамы һәм Тынычлык урамы, Яншык авылы Мәктәп урамы, Кече Укмас авылы Комсомол урамы юллары ремонты өчен;
- МТЗ-82 тракторын тоту өчен;
- Яншык авылы зиратын әйләндереп алу өчен материаллар алуга;
- су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү өчен.

"ЯКЛЫЙМ" "КАРШЫ"

6. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Бәтке авылы,Ленин урамы,4 йорт; Яншык авылы, Җинүнен 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов